**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«27» сентябрь 2019 ел № 9/1

«Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 18 сентябрендәге «Җир салымы турында» 9/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып, әлеге карар нигезендә муниципаль берәмлек территориясендә түләнергә тиешле җир салымы билгеләнә һәм гамәлгә кертелә һәм «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 18 сентябрендәге «Җир салымы турында» 9/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктны өстәргә:

«13) оешмаларга – «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә аккредитацияләнгән, сәнәгать (индустриаль) паркы биләгән җир кишәрлекләре.».

2. Әлеге карарны Бәтке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бәтке авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.А. Ионычев